## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Нәрсә якшы?**

Мәче, Әтәч, Эт һәм Кәҗә бер ишегалдында яшиләр икән. Кич булды исә, алар сарай алдында җыелалар да үз эшләре турында сөйләшә башлыйлар. Ләкин һич тә килешә алмыйлар: “Дөньяда иң тәмле әйбер нәрсә?”- дип сүз көрәштерәләр икән.

- Сөттән дә тәмле нәрсә юк, - дигән Мәче. – Тычкан да начар түгел, ләкин аны тотуы кыен.

- Сөт тәмлемени ул?! Ә менә солы яки ярманы әйтсәң дә ярый, алардан да якшы нәрсә дөньяда юк,- ди икән Әтәч.

- Сез, туганнар, юкны сөйлисез, дөресен әйткәндә, иң тәмлесе сөяк инде. Мин үз гомеремдә күпме сөяк кимердем, аннан да тәмле азык тапмадым, - дигән Сарбай.

- Ашар өчен хуш исле печәннән дә якшысы юк инде аның,- ди икән Кәҗә.

Алар шулай кич буе бәхәсләшәләр-бәхәсләшәләр дә, “Нәрсә якшы?” дигән сорауга һич җавап таба алмыйча, тагын таралалар икән. (130 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

# 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Керпе**

Бу хәл күп еллар элек булды. Без ул вакытта авылда тора идек. Җәйге эссе көн. Авылның бөтен кешесе болында печән чаба. Минем абый да шунда китте. Өч сәгатьтән ул ашарга кайтты. Карыйм, күлмәк эчендә нидер бар. Ул керпе булып чыкты.

Шул көннән керпе бездә тора башлады. Башта аңа авыр булды. Ул өстәл астына да, карават астына да кереп кача иде. Аннан соң ул безнең янга да чыга башлады. Без аңа иртән һәм кичен – сөт, ә көндез ит бирәбез. Кич белән барыбыз да йокларга ятабыз. Керпе генә йокламый. Ул тычканнар тота.

Салкын буранлы кыш җитте. Аның артыннан матур яз килде. Керпе һаман бездә яшәде. Җәйге көннәрнең берсендә без аны ишегалдына чыгардык. Шуннан соң без аны күрмәдек, ул югалды. Үзенең болынына киткәндер инде. (121 сүз).

# 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Куян баласы**

Алия дәү әнисе белән йөрергә ярата. Алар болынга да, басуга да гел бергә баралар. Бүген басуда Алия куян баласы күрде. Куян баласы ни өчендер качмады. Алия тиз генә аны колакларыннан тотып алды. Куян баласы Алиянең кулларыннан сикереп төшергә тырышты. Ниһаять, ул арды, тынычланды. Куян баласы йөри алмый, аның аяклары авырта икән. “Дәваларбыз”,- диде әбисе. Алар куян баласын өйгә алып кайттылар. Алия аны бүлмәгә җибәрде, ә ишекне япты.

Берничә көннән куян баласы сикерә, йөгерә, керт-керт итеп кәбестә яфраклары ашый башлады. Әй шатланды Алия!

Ә беркөнне ул ялгыш ишекне ачык калдырды. Йөгереп кайтты, бүлмәдән куян баласын эзли башлады – таба алмады. Кыз елап җибәрде.

- Елама, кызым, - диде әбисе. Инде аның аяклары төзәлде. Куян баласы хәзер элеккечә йөгерә ала, ул әнисе янына урманга китте. Сиңа рәхмәт әйтте. Хайваннар ирек яраталар бит алар.

Йомшак куян баласы әнисен сагынган. Алия моны аңлый иде. Ул аларның очрашуы турында уйлады. (144 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

# 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Чыршы бәйрәме**

Тиздән чыршы бәйрәме якынлаша. Без, абыем белән икәү, бик матур чыршы сатып алдык та, чанага салып, чыжлатып, алып кайтып киттек. Өйгә кайткач, чыршыны бер почмакка сөяп куйдык. Ул озын, очлары түшәмгә җитеп тора. Ә үзе ямь-яшел. Әнием дә, дәү әнием дә бик сокландылар. Песи дә килде. Ул алгы тәпиләре белән чыршының ботакларын тотып-тотып карады.

Аннары абыем белән без икәү чыршыны бизәргә тотындык. Әнием дә бизәште. Чыршының ботакларына йолдызлар, ялтыравыклы шарлар, ука кәгазь тасмалар элдек. Аю баласы да, куянны да, филне дә, этәчне дә утырттык.

Шуннан соң абыем җепкә тезелгән төрле төстәге вак лампочкалар белән чыршыны уратып куйды. Лампочкалар янгач, чыршы ялт итеп балкып китте. Мин бик шатландым. Чыршы бөтенләй матур итеп бизәлеп беткәч, песи килеп җитте дә, күзләрен ялтыратып, чыршыга карап тор башлады, уенчыклар белән уйнарга кереште. (130 сүз).

# 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Базарда**

Радик әти-әнисе белән базарга килде. Менә бу рәттә яшелчә бик күп. Кәбестә, кишер, чөгендер, кыяр, помидор, суган, сарымсак, баклажан саталар.

Җиләк-җимеш тә күп. Кәрзин-кәрзин алма, әфлисун, лимон, чия, карлыган, җир җиләге, кара җиләк, слива, кура җиләге...

Әнисе салат өчен яшелчә, кайнатма өчен кура җиләге, карлыган сатып алды. Бу базарда бәяләр очсызрак икән.

Ит рәтендә сыер, сарык, дуңгыз итләре, тавык саталар. Әнисе бер тавык алды. Кич белән тәмле токмач булачак! Радик токмачны бик ярата.

Радикның әбисе өрек белән чәй эчәргә ярата. Шунда ук йөзем, күрәгә, әстерхан чикләвеге, как, кара җимеш, хөрмә, кипкән алма, груша, инҗир дә бар икән. Ләкин һәммәсе бик кыйбат!..

Базарда чәчәкләр дә күп икән. Шундый матурлар!

Өстәлләрдә төрле-төрле гөмбәләр: ак гөмбә, гөреҗдә, каен гөмбәсе, әтәч гөмбәсе, майлы гөмбә...

Әнә бер әби көнбагыш сата. Стаканы 3 сум. Әнисе Радикка бер стакан көнбагыш алды. (134 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Җиләклектә**

Маратны йокыдан дәү әтисе уятты.

-Тор, улым, җиләккә барабыз.

Җиләк сүзен ишетүгә Маратның йокысы әллә кая качты. Көн матур булырга охшый. Дәү әтисенең мотоциклы бигрәк яхшы йөри. Йөрми, оча, шундый рәхәт. Менә берничә минуттан инде алар җиләкле тауда иделәр. Килеп җитүгә, бер-берсе белән ярыша-ярыша, җиләк җыярга керештеләр. Маратка җиләк җыю кызык та, рәхәт тә булды.

Җиләкләр дә качышлы уйныйлар икән бит. Иң эреләре, иң кызыллары яфрак арасында, күренмиләр дә. Эзләп тапкач, авызга кабасы килә үзләрен. Ә инде бер тәмен белдеңме... Савытка бер дә төшәселәре килми. Гел авызга керергә генә торалар. Савытым тулсын дисәң, үз-үзеңне җиңәргә кирәк. Тулган савытыңны зур чиләккә бушаткандагы рәхәтлекне сөйләп тә, язып та бетерә торган түгел.

Бүгенге көн Маратны күп нәрсәләргә өйрәтте. Ә бу бит каникулның бары тик бер көне генә иде. Алда әле, башланган булса да, бер ай! (135 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

# 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Ай белән кояш.**

Элекке заманда Ай белән Кояш гел бер җирдә генә торырга теләгәннәр. ошлар моңа риза булганнар һәм кул куйганнар.

Менә алар, бөтен кошларны җыеп, шул турыда сөйләшкәннәр. Кошлар моңа риза булганнар һәм кул куйганнар.

Болар арасында бер генә кош-Ярканат кына кул куярга теләмәгән, ди. Бүтән кошлар Ярканаттан сораганнар:

- Барлык кошлар кул куйганда, син генә нигә кул куймадың?-дигәннәр.
- Мин кулны шуңа куймадым: Кояш белән Ай бер җирдә генә торсалар, Кояш төшкән җирдә игеннәр үсәр, Кояш төшмәгән җирдә үсмәс, -дигән Ярканат.

Шуннан соң бүтән кошлар да әйткәннәр:

- Дөрес әйтә, Кояш төшмәгән җирдә иген үсми.

Кошлар: “Ай белән Кояш бер җирдә генә тормаска, ә әйләнеп йөрергә тиеш”, - дип карар чыгарганнар.

Шуннан соң Кояш Ярканатка әйткән:

- Мин сине үземнең яктылыгымда йөртмәячәкмен, - дигән. Шуңа күрә Ярканат көн яктылыгына чыгып йөри алмый икән.

Ай Ярканатка бер сүз дә әйтмәгән, шуңа күрә ул ай яктысында да бик әйбәт йөри икән. (148 сүз).

# 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Ак песи**

Күптән түгел төзелгән матур йортның беренче подъездына өч малай, өч кыз күчеп килделәр. Алар бик тиз дуслаштылар. Ишегалдында гел бергә уйнадылар,вакытны бик матур үткәрделәр.

Менә көз җитте. Агач яфраклары саргайды. Яңгырлар ява башлады. Кошлар җылы якларга очып киттеләр.

Яңгырлы бер көндә Айдар балалар бакчасына бармады. Киенеп, урамга чыгып китте. Урамда кояш юк иде. Салкын җил исә. Айдарга күңелсез булып китте, шуңа күрә өйгә керергә теләде.

Подъезд ишеген ачкан иде, кемдер нечкә тавыш белән:

-Мияу! - дип кычкырып куйды. Почмакта ап-ак песи утыра иде.

-Туңгансың бит, әйдә, безгә керәбез, песикәй, мин сиңа ипи белән сөт бирермен, - диде Айдар. Ләкин песи урыныннан тормады.

Айдар, тәлинкә белән җылы сөт һәм йомшак ипи кисәге алып чыгып, аның алдына куйды. Ашагач, песи тәмле йокыга китте.

Кичен дуслары бакчадан кайтты. Айдар аларга яңа дусты турында әйтте. Дуслары да песине бик яраттылар. Аннары песигә исем эзли башладылар. (140 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Һөнәр**

Чынлап та, тормышта бик күп һөнәрләр бар: укытучы, табиб, сатучы, инженер, шофер һәм башкадар. Хәзер менеджер, брокер, промоутер кебек яңа һөнәрләр дә барлыкка килде. Шулар арасыннан үзең яраткан профессияне сайлау җиңел түгел. Минем туризм белән бәйле һөнәр сайлыйсым килә. Төрле илләрдә булырга, туристик бизнес ачарга телим. Мин бик тырышып инглиз телен, географияне өйрәнәм, башка фәннәрдән дә яхшы укырга тырышам.

Минем әти-әнием – югары белемле белгечләр. Әнием – экономист (икътисадчы), әтием – заводта мастер. Алар үз эшләрен яраталар һәм миңа да үзем яраткан эшне сайларга киңәш бирәләр.

Гомумән, миңа күп һөнәрләр ошый. Кайчакта минем дизайнер яки эколог буласым килә. Үзем яраткан һөнәрне табармын дип уйлыйм. (100 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Сәламәт тәндә – сәламәт акыл**

"Сәламәт тәндә – сәламәт акыл", ди халык. Көндәлек режим, шәхси гигиена таләпләрен үтәү, чыныгу күнегүләрен үткәрү, физзарядка ясау, саф һавада йөрү, дөрес туклану, чиста һәм пөхтә булу-болар барысыда физик сәламәтлек нигезе. Ләкин еш кына сәламәт булу өчен бөтен шартларны үтәгән кеше дә авырый. Ни өчен шулай икән? Бу сорауга җавап бирү өчен, җан тынычлыгы белән тән саулыгы арасындагы нинди бәйләнеш барлыгын ачыкларга кирәктер. Нерв системасы какшаган баланың физик сәламәтлеге нык була алмый. Ә физик сәламәтлекнең нигезе – нерв системасының ныклыгы, тынычлыгы ул. Шуны онытмагыз: безнең яхшы һәм зарарлы гадәтләребезне балаларыбыз теләгебезгә бәйсез рәвештә кабатлыйлар. Әйдәгез, без аларга һәрчак яхшы үрнәк кенә күрсәтик һәм мәктәп белән берлектә балаларны сәламәт яшәү рәвешенә өйрәтик. (108 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Карлар ява**

Тышта ап-ак кар ява. Агач ботакларына мамыктай йомшак бәс куна. Бакча аеруча ямьләнеп киткән. Илгизәргә бу күренеш бик ошады. Ул, чанасын алып, урамга чыкты. Алар, күрше малайлары беләнбергәләп, бакча артындагы куаклыкта туйганчы уйнадылар. Йомшак карны тәгәрәтеп шар ясадылар. Ап-ак шар тәгәрәгән саен калыная, зурая барды. Балалар куандылар:

— Ай-яй, нинди матур булды!

— Әйдә, тагын тәгәрәтик әле!

— Әйдә, әйдә!

Балалар кардан ак аю һәм Кар бабай сыны ясап куйдылар. Ал арның шатлыгы тагы да арта:

— Кулына таяк тоттырыйк!

— Күзенә күмер куйыйк!

— Борын да ясыйк! Борыны кып-кызыл булсын!

Балалар шулай эшләделәр дә. Берсе өйдән кишер алып чыкты. Шуннан Кар бабайга борын ясап куйдылар. Аннан соң үзләре, читтән карап, рәхәтләнеп көлештеләр. (107 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

# 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Табиб**

Табиб булырга җыенган кешегә нинди сыйфатлар кирәк? Әлбәттә, ул кешеләрне яратырга һәм ягымлы булырга тиеш. Чөнки табибның вазифасы – авыруларның газапларын җиңеләйтү һәм үлемнән коткарып калу. Табиб булу өчен кеше тормышта да, эштә дә шәфкатьле, җаваплы, акыллы, гадел булырга тиеш. Эгоист кеше табиб була алмыйдыр дип уйлыйм. Табиб кыю булырга тиеш. Аңа эпидемия булган урынга беренче булып барып керергә туры килә бит. Табиб игътибарлы да булырга тиеш. Игътибар белән карамаган табибка авыру ышанмаячак, ә табибның уйламыйча әйткән сүзе, авыруны куркытып, терелүгә ышанычын бетерергә мөмкин. Табибка күзәтүчән һәм сабыр булырга кирәк. Ул авыру серен саклый белергә тиеш. Аңа әле тәвәккәл булырга да кирәк. Табиб — бик дәрәҗәле, кирәкле кеше. (106 сүз).

# 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Хезмәт**

Без кулланган һәм алардан башка бер көн дә яши алмаган барлык нәрсәләр дә диярлек – кеше кулының эше, хезмәт нәтиҗәсе. Кеше үзенең хезмәте, куллары, акылы һәм энергиясе тудырган әйберләр белән данлыклы.

Хезмәт кешенең үзен дә барлыкка китергән, шуның нәтиҗәсендә кеше камилләшә бара. Хезмәттә кешенең сәләте һәм таланты ачыла, белеме киңәя. Кеше физик яктан ныгый, аның ихтыяры һәм характеры чыныга. Чөнки хезмәт ул – көч кую да, түземлелек тә, тырышлык та, тегәллек тә, пөхтәлек тә, башкаручанлык та, тапшырылган эшкә җаваплылык та.

Безнең ил – үзеңнең көчеңне һәм сәләтеңне кулланырга мөмкин булган гаять зур эшчәнлек мәйданы ул. Берәүләр төрле-төрле машиналар төзи, икмәк үстерә, файдалы казылмалар чыгара. Икенчеләре китаплар, картиналар, музыка яза, спектакльләр куя, кинофильмнар төшерә. Өченчеләре энергиянең яңа төрләрен эзли, табигать серләрен ача, галәмне өйрәнә. (120 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

# 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Ашханәдә**

Беркөнне без әни белән ашханәгә кердек. Бу ашханәгә без еш керәбез, анда бик тәмле пешерәләр. Ул бездән ерак урнашмаган.

Ашханәдә төрле ризыклар бар. Беренчегә токмачлы аш, кәбестәле аш, чөгендерле аш бирәләр иде. Әни кәбестәле аш алды, чөнки ул токмачлы аш яратмый. Ә мин чөгендерле аш алдым. Икенчегә пылау, бәрәңге боламыгы белән кыздырылган тавык, карабодай боткасы белән ит, пилмән, токмач белән пешкән балык бар иде. Без икебез дә бәрәңге боламыгы белән кыздырылган тавык алдык. Әни үзенә кишер салаты, ә мин каймаклы кыяр белән помидор салаты алдым. Беренче һәм икенче ашлардан соң без баллы чәй эчтек.

Әфлисун һәм алма согы сатып алдык. Өйдә безгә барыбер ашарга пешерергә кирәк, чөнки сәгать җидедә әти эштән кайта. (112 сүз).

# 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**